ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2023 г. Заинск № 245

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган РФ гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында" 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 декабрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 644 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары (08.07.2022 ел, № 337; 23.05.2022 ел, № 249; 03.10.2022 ел, № 506; 07.12.2022 ел, № 620 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм алу тәртибе» 2 нче кушымтасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве күләмен исәпләү, билгеләү һәм үзгәртү тәртибе II өлешендә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Бишенче абзацның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия

Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасында формалашкан “Алга” һәм “Тимер” батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнарның, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнарның, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның балалары өчен ата-ана түләве алынмый (законлы вәкилдән бирелгән гариза һәм хәрби комиссариаттан белешмә, яки эш урыныннан белешмә нигезендә)».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 01 апрельдән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42